ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.10.2020 № 819

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 сентябрендәге 702 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 03.09.2020 ел, №702 карары белән расланган җир кишәрлегеннән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән беренчел баш тартканда күрсәтелмәгән документларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен йә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны яисә мәгълүматны таләп итү. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күп функцияле үзәккә әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөмкин.».

5.4 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, йә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре, оешма, әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, аларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган карарлар һәм

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган аларның җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме».

2.15 пунктының 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ) аша муниципаль хезмәт күрсәтү, КФҮнең ерактагы эш урыннары аша башкарыла. Экстриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт һәм комплекслы соратып алу составында күрсәтелми.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.А.Газизуллин